КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1053

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2005 ел, 20 апрель, 192 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 7 июнь, 251 нче; 2006 ел, 24 апрель, 209 нчы; 2006 ел, 15 июнь, 308 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бирергә:

«Татарстан Республикасының авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендәге дәүләт учреждениеләре, шул исәптән дәүләт социаль хезмәтләр системасының социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре хезмәткәрләренә – Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы һәм коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары чикләрендә торак, җылылык, яктырту өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә. Әлеге социаль ярдәм күрсәтү чарасы шулай ук авыл җирендә яшәүче һәм авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләрендә, Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт

күрсәтү учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән әлеге хезмәткәрләр арасыннан пенсиягә чыккан гражданнарга, 60 һәм 55 яшь тулган гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), шулай ук 2018 елның 31 декабре хәленә карата «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүче, әмма 60 һәм 55 яшь тулмаган гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) бирелә;»;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ нче пункт өстәргә:

«$1^1$. Авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм эшләүче Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының, муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә, әлеге мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, әлеге мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы чикләрен чикләмичә, торак, җылылык, яктырту өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә компенсация бирелә дип билгеләргә. Әлеге социаль ярдәм күрсәтү чарасы шулай ук авыл җирендә яшәүче һәм авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль белем бирү оешмаларында кимендә 10 ел эшләгән әлеге хезмәткәрләр арасыннан пенсиягә чыккан гражданнарга, 60 һәм 55 яшь тулган гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), шулай ук 2018 елның 31 декабре хәленә карата «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүче, әмма 60 һәм 55 яшь тулмаган гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) бирелә.»;

3 нче пунктта «хезмәткәрләре өчен» сүзләреннән соң «(бу карарның $1^1$ нче пунктында күрсәтелгән гражданнардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 июнь, 251 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 432 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 961 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта «1 нче пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре белгечләренә» сүзләрен «1, $1^1$ нче пунктларында күрсәтелгән гражданнарның аерым категорияләренә» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесенең» сүзләрен-

нән соң «яки авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) урнашкан муниципаль мәгариф оешмасының (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесенең яки муниципаль мәгариф оешмасының)» сүзләрен өстәргә;

11 нче пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре» сүзләреннән соң «яки муниципаль мәгариф оешмалары» сүзләрен өстәргә һәм «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) урнашкан» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 нче пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе яки муниципаль мәгариф оешмасы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2005 ел, 20 апрель, 192 нче карарының 1, $1^1$ нче пунктларында күрсәтелгән вазыйфалар категорияләре буенча хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату (әлеге карарның 1, $1^1$ нче пунктлары нигезендә субсидия-ташлама бирелә торган очраклардан тыш);»;

Тәртипкә теркәлгән кушымтада «атасының исеме» сүзләрен «атасының исеме (булганда күрсәтелә)» сүзләренә алыштырырга һәм «Ф.Ис.Ат.ис.» аббревиатурасын «Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин